КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 декабрь г.Казань № 1252

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары структурасын һәм штат расписаниесен раслау турында» 2007 ел, 12 ноябрь, 626 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының җәмәгать судьялары аппаратлары структурасын һәм штат расписаниесен раслау турында» 2007 ел, 12 ноябрь, 626 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 21 декабрь, 738 нче; 2010 ел, 29 ноябрь, 957 нче; 2013 ел, 9 август, 556 нчы; 2013 ел, 11 декабрь, 976 нчы, 2014 ел, 17 март, 163 нче, 2016 ел, 14 гыйнвар, 11 нче; 2016 ел, 11 май, 294 нче; 2017 ел, 29 сентябрь, 732 нче; 2017 ел, 28 декабрь, 1069 нчы; 2018 ел, 19 февраль, 96 нчы; 2017 ел, 27 апрель, 302 нче, 2020 ел, 17 март, 194 нче; 2020 ел, 2 октябрь, 893 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «766,5» һәм «11 645 172,0» саннарын тиешенчә «786,5» һәм «11 951 974,0» саннарына алмаштырырга;

күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларының штат расписаниесен яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына законнар нигезендә әлеге карарның 1 пунктын гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган оештыру карарларын кабул итәргә.

3. Бу карарның 1 пункты 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 ноябрь, 626 нчы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 30 декабрь, 1252 нче карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларының штат расписаниесе

| Вазыйфа атамасы | Саны, берәмлек-ләре | Вазыйфаи оклад, тариф ставкасы, сум | Хезмәт өчен түләүнең айлык фонды, тариф фонды, сум |
|---|---|---|---|
| Консультант | 155 | 18 719,0 | 2 901 445,0 |
| Суд утырышы секретаре | 190 | 18 719,0 | 3 556 610,0 |
| 2 разрядлы өлкән белгеч - канцелярия мөдире | 165 | 15 201,0 | 2 508 165,0 |
| 2 разрядлы белгеч | 176 | 14 465,0 | 2 545 840,0 |
| Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре барлыгы | 686 | - | 11 512 060,0 |
| Өлкән белгеч | 14 | 16 098,0 | 225 372,0 |
| 5 разрядлы машина йөртүче | 2 | 2 953,0 | 5 906,0 |
| Биналарга комплекслы хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау буенча 4 разрядлы эшче | 5 | 2 660,0 | 13 300,0 |
| Биналарга комплекслы хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау буенча 3 разрядлы эшче | 15 | 2 539,0 | 38 085,0 |
| Җитештерү һәм хезмәт бүлмәләрен 2 разрядлы җыючы | 64,5 | 2 438,0 | 157 251,0 |
| Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына кертелмәгән хезмәткәрләр барлыгы | 100,5 | - | 439 914,0 |
| Барлыгы җәмәгать судьялары аппаратлары буенча | 786,5 | | 11 951 974,0 |

_______________________